ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

______24.12.2025___________ № 922______

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районының Биектау т/юл ст. пос. нан 11 километрдан ераграк урнашкан ерактагы һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарлар китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнары өлешен каплауга Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 2583 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органы структур бүлекчәләрендә кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районының Биектау т/юл ст. пос. нан 11 километрдан ераграк урнашкан ерактагы һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарлар китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнары өлешен каплауга Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 2583 номерлы карары (21.10.2022 № 1011, 16.05.2022 №491, 04.08.2020 № 595, 04.10.2019 №1680 редакциясендә) белән расланган Биектау муниципаль районының Биектау т/юл ст. пос. нан 11 километрдан ераграк урнашкан ерактагы һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарлар китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнары өлешен каплауга Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча комиссия составына (2 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан чыгарырга: комиссия рәисе Шәйдуллин Дамир Фәрит улын - Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен;

Нигъмәтуллина Айгөл Рәшит кызын, Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгын;

Гайфуллина Алинә Рафис кызын – Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы урынбасарын.

Комиссия составына кертергә: Хәкимуллин Рамил Фатих улын - Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен һәм комиссия рәисе итеп билгеләп куярга;

Минемуллин Рушан Раиф улын - Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгын һәм комиссия секретаре итеп билгеләп куярга;

Адиярова Ләйсән Хәйдәр кызын – Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгечен һәм комиссия секретаре итеп билгеләп куярга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы сайтына: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин